Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын кулланууның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышулар башлану турында
ХӘБӘР ИТҮ

Әлеге белдерү белән Җир кишәрлеген куллануның «элемтә» шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында кадастр номеры 16:15:100101:1175 булган җир кишәрлеге өчен Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының 2026 елның 10 августындагы 63/п номерлы карарына туры китереп җәмәгатьчелек белән фикер алышулар башлануы турында хәбәр ителә.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге: фото материаллар

Проект буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышулар үткәрү тәртибе һәм вакыты: 2026 елның 17 августыннан 2026 елның 5 сентябренә кадәр.

Җәмәгатьчелек белән фикер алышулар РФның Җир төзелеше кодексы, «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законы, Югары Ослан районы муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан районы муниципаль берәмлегендә шәһәр төзелеше өлкәсендәге проект буенча җәмәгать фикер алышуларын, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү турында Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Советы карары белән расланган Нигезләмәгә туры китереп үткәрелә.

Иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар даирәсе: кызыксынган затлар.

Җәмәгатьчелек белән фикер алышулар үткәрелә торган территория: Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Мәйдан авыл җирлеге, Мәйдан авылы.

Проектның җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда карала торган экспозициясен ачу урыны һәм вакыты: 2026 елның 17 августыннан мәгълүмати стендларда:

- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 нче йорт адресы буенча;
- Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча: 422587, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Мәйдан авылы, Совет урамы, 55нче бина

Проект экспозициясен үткәрү вакыты: 17.08.2026 елдан 05.09.2026 елга кадәр.

Экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: дүш - җомга 09-00 сәг.тән 16-00 сәг.кә кадәр

Иҗтимагый фикер алышуларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: Проектны иҗтимагый фикер алышуларда карауга булган 17.08.2026 елдан 05.09.2026 елга кадәр булган барлык вакыт эчендә, Югары Ослан районының http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ сәхифәсендә, «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» бүлегендә, экспозиция үткәрү вакытында, идентификация үткәргән

иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылары, бу проектка караган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт аша;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язма рәвештә - даими рәвештә эшләүче комиссиягә яки иҗтимагый фикер алышулар яки тыңлаулар үткәрү буенча комиссиягә Югары Ослан муниципаль районының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге проектлар буенча (422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18нче йорт адресы буенча: тел: 8(84379) 2-16-59;

3) «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналына язу юлы белән.

Җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт һәм аңа мәгълүмати материаллар, яисә мондый проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак, шулардан файдаланып җәмәгать фикер алышулары үткәреләчәк мәгълүмати системалар турында мәгълүмат: https://pravo.tatarstan.ru һәм https://verhniy-uslon.tatarstan.ru. Югары Ослан муниципаль районы сайтында.

Җәмәгать фикер алышуларында карарга тапшырылачак проект урынлаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат, һәм аңа мәгълүмат материаллары: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru. Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты.

Әлеге белдерүне бастырырга: 11.08.2026 елдан соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» челтәрендәге Югары Ослан муниципаль районы сайтында: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru. урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе А.А. Әхмәтшин